# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлеге составына керүче Дусай-Кичү торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**28 ноябрь 2024 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1,56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» №45-ТРЗ 2024 елның  28 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:  «Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Дусай-Кичү торак пункты территориясендә 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы, сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларына  хезмәткә чакырылган гражданнардан , махсус хэрби операциядэ катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә ,   һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгэ Сез ризамы?

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту - Дусай-Кичү торак пунктындагы Җәлил урамындагы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, эш өчен килешү буенча түләү).»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 69 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 36 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 36 катнашучы тавыш бирде;

җыенда 0 катнашучы «каршы» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Дусай Кичү торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2: «Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Дусай-Кичү торак пункты территориясендә 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы, сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан , махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә , һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгэ Сез ризамы?

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту - Дусай-Кичү торак пунктындагы Җәлил урамындагы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, эш өчен килешү буенча түләү).»- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яңа Мәлкән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ____________ Нәҗметдинов З. И.

Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгы,

Совет рәисе____________________ Нәҗметдинов З. И.